| АЛЕКСЕЕВСКИЙ РАЙОННЫЙ СОВЕТ АЛЕКСЕЕВСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ АЛЕКСЕЕВСК МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ АЛЕКСЕЕВСК РАЙОН СОВЕТЫ |
|---|---|---|

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

04.02.2026 № 33

п.г.т. Алексеевское

**Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районы муниципаль милегендә булган һәм сатуларсыз арендага бирелгән җир кишәрлекләре өчен аренда түләве күләмен билгеләү Тәртибен раслау турында**

Россия Федерациясе Җир кодексының 39.4 статьясындагы 2 пунктының 3 пунктчасына, 39.7 статьясындагы 3 пунктчасына, 39.25 статьясындагы 2 пунктының 3 пунктчасына, 39.28 статьясындагы 5 пунктының 3 пунктчасына, «Россия Федерациясе Җир кодексын гамәлгә кертү турында «2001 елның 25 октябрендәге 137-ФЗ номерлы Федераль законга, Россия Федерациясенең 1998 елның 31 июлендәге 145-ФЗ номерлы Бюджет кодексының 41 статьясындагы 6 пунктына,Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2009 елның 16 июлендәге 582 номерлы «Дәүләт милкендәге яисә муниципаль милектәге җир кишәрлекләрен арендага алганда аренда түләвен билгеләүнең төп принциплары турында һәм аренда түләве күләмен, шулай ук Россия Федерациясе милкендәге җирләр өчен аренда түләвен кертү тәртибен, шартларын һәм срокларын билгеләү Кагыйдәләре хакында» карарына, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Җир өчен аренда түләве турында» 1995 елның 09 февралендәге 74 номерлы карарына, Татарстан Республикасы «Алексеевск муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Уставына туры китереп

**Алексеевск муниципаль районы Советы карар кабул итте:**

1. Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районы муниципаль милкендәге һәм сатулар үткәрмичә генә арендага бирелгән җир кишәрлекләре өчен аренда түләве күләмен билгеләү тәртибен (Кушымта)расларга;
2. Әлеге карарны Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге Алексеевск муниципаль районының рәсми порталында, Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында урнаштырырга.
3. «Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районы муниципаль милкендәге җир кишәрлекләре өчен аренда түләве күләмнәрен билгеләү тәртибе турында Нигезләмә хакында» 2017 елның 11 июлендәге 106 номерлы, «Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районы муниципаль милкендәге җир

кишәрлекләре өчен аренда түләве күләмнәрен билгеләү тәртибе турында Нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында» 2019 елның 04 февралендәге 224 номерлы Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районы Советы карарының үз көчен югалтуын танырга.

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе О.Н.Леденцовка йөкләргә.

**Алексеевск муниципаль**
**районы башлыгы,**
**Совет рәисе** **С.А.Демидов**

Татарстан Республикасы
Алексеевск муниципаль районы
Советының 04.02.2026 ел, № 33
карарына кушымта

**Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районы муниципаль милегендә булган һәм сатуларсыз арендага бирелгән җир кишәрлекләре өчен аренда түләве күләмен билгеләү**
**Тәртибе**

1. Әлеге Тәртип Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районы муниципаль милкендәге һәм сатуларсыз арендага бирелгән җир кишәрлекләре өчен аренда түләве күләмен билгеләү максатларында билгеләнгән.

Әлеге тәртип, 13 пункттан тыш, җир кишәрлекләрен сатулар нигезендә арендага бирү очракларына кагылмый.

2. Биналарның, корылмаларның бер өлешен арендага биргәндә бина, корылма биләгән җир һәм аларны карап тоту өчен кирәкле кишәрлекләр өчен аренда түләве алына. Җир өчен аренда түләве бинадан яки корылмадан файдаланган өчен аренда түләвенә кертелә.

3. Җир салымын түләү буенча гамәлдәге законнарда билгеләнгән ташламалар, җирле үзидарә органнарының норматив актларында билгеләнгән өстәмә ташламалар юридик затларга һәм җирне арендалаучы гражданнарга кагыла.

4. Җир өчен аренда түләве буенча ташламалары булган арендатор җир кишәрлеген ташламасы булмаган затка субарендага биргән очракта, субарендатор җир өчен аренда түләвен гомуми нигезләрдә кертергә тиеш.

Җир өчен аренда түләве буенча ташламасы булмаган арендатор җир кишәрлеген ташламасы булган затка субарендага биргән очракта, арендатор җир өчен аренда түләвен гомуми нигезләрдә кертә.

5. Россия Федерациясе Җир кодексының 49 статьясындагы 2 пунктында каралган объектларны урнаштыру өчен, шулай ук җир асты байлыкларыннан файдалануга бәйле эшләр башкару өчен бирелгән җир кишәрлекләре өчен аренда түләве федераль башкарма хакимият органнары тарафыннан расланган аренда түләве ставкалары белән исәпләнә.

6. Җир кишәрлекләреннән файдаланган өчен еллык аренда түләве күләме түбәндәге формула буенча исәпләнә:

А = Кс х Рс х Кф,

монда:

А - җир кишәрлегеннән файдаланган өчен еллык аренда түләве күләме;

Кс - җир кишәрлегенең кадастр бәясе;

Рс - җир салымы ставкасы күләме;

Кф - әлеге Тәртипкә кушымта нигезендә җир кишәрлегеннән файдалану төрен исәпкә ала торган төзәтмә коэффициенты.

7. Җир өчен аренда түләве арендатор тарафыннан ай саен, хисап аеның 30 көне тәмамланганчы, җир кишәрлеген арендага бирү вакытыннан алып шартнамәнең гамәлдә булу чоры дәвамында кертелә.

Түләнмәгән суммага аренда түләве вакытында кертелмәгән очракта, түләнмәгән һәр көн өчен аренда түләүләренең вакыты чыккан суммасыннан 0,1% күләмендә пенялар исәпләнә.

8. Дәүләт күчемсез мөлкәт кадастрында җир кишәрлегенең кадастр бәясе билгеләнмәгән йә 0 яисә 1 сум күләмендә күрсәтелгән очракта, аренда түләве җир кишәрлегенең базар бәясе нигезендә исәпләнә.

9. Җир кишәрлегеннән рөхсәт ителгән файдалану төре буенча Кф коэффициенты кушымта нигезендә кулланыла һәм җирле үзидарә органнары тарафыннан билгеләнә.

10. Җир кишәрлеге өчен аренда түләвенең минималь күләме мондый җир кишәрлеге өчен исәпләнә ала торган җир салымыннан түбәнрәк була алмый.

11. Милеге чикләнмәгән, юридик затларның даими (вакыты чикләнмәгән) файдалану хокукындагы һәм алар тарафыннан аренда хокукына яңадан рәсмиләштерелгән җир кишәрлекләреннән файдаланган өчен аренда түләве:

арендалана торган җир кишәрлекләренең кадастр хакының ике проценты;

авыл хуҗалыгы билгеләнешендәге җирләрдән арендалана торган җир кишәрлекләре кадастр хакының уннан өч проценты;

арендага алынган, әйләнештән алынган яисә әйләнештә чикләнгән җир кишәрлекләренең кадастр бәясенең бер ярым проценты.

12. Җир кишәрлеген арендалау шартнамәсе Россия Федерациясе Җир кодексының 39.7 статьясындагы 5 пункты нигезендә төзелгән очракта җир кишәрлекләре өчен аренда түләве күләме мондый җир кишәрлегенә карата исәпләнгән җир салымы күләмендә билгеләнә.

13. Җир кишәрлегенең кадастр бәясе үзгәргәндә аренда түләве җир кишәрлегенең кадастр бәясе үзгәргән елдан соң киләсе елның 1 гыйнварына яңадан исәпләнергә тиеш.

Җир кишәрлегенең кадастр бәясе үзгәрүгә бәйле рәвештә аренда түләвен үзгәртү мөмкинлеге җир кишәрлеген арендалау шартнамәсендә карала.

14. Әгәр арендатор ягында берничә зат чыгыш ясаса, аларның һәркайсы өчен аренда түләве җир кишәрлеген арендалау шартнамәсе нигезендә арендага алынган мөлкәткә хокукта аларның өлешенә пропорциональ рәвештә билгеләнә

15. Әгәр җир кишәрлегендә берничә төрле файдалану гамәлгә ашырылса, аренда түләвен исәпләү максатларында җир кишәрлегеннән файдалану төрен исәпкә ала торган иң зур төзәтмә коэффициенты кулланыла.

16. Әгәр җир кишәрлекләрендә офис инфраструктурасыннан файдаланып (үзәкләштерелгән кабул итү бүлмәләрен, очрашулар үткәрү өчен бүлмәләрне, офис җиһазларын, парковкаларны кертеп), бинаның, төзелешнең, корылманың гомуми мәйданының 20 процентыннан артмаган мәйданда җитештерү эшчәнлеге башкарылса, аренда түләве җитештерү эшчәнлеге өчен кулланыла торган ставка буенча алына.

17. Җир кишәрлекләреннән файдаланмау йә максатчан файдаланмау фактлары билгеләнгәндә аренда түләве җир законнарын бозуны бетергән вакытка кадәр аренда шартнамәсе буенча билгеләнгән икеләтә аренда түләве күләмендә билгеләнә.

Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районы муниципаль милкендәге һәм сатуларсыз арендага бирелгән җир кишәрлекләре өчен аренда түләве күләмнәрен билгеләү Тәртибенә кушымта

Җир кишәрлегеннән файдалану төрен исәпкә ала торган төзәтү коэффициентлары
Исемлеге

| Җир кишәрлегеннән файдалану төре | Коэффициент |
|---|---|
| Медицина, социаль, психологик, юридик ярдәм күрсәтү өчен билгеләнгән хәйрия фондлары биналары, төзелмәләре һәм корылмалары өчен (төзелеш чорын да кертеп) | 0,01 |
| Махсус, хәрби, физик әзерлек һәм спорт уку үзәкләрен урнаштыру өчен дәүләт милкендәге һәм коммерциягә карамаган автоном оешмаларга түләүсез файдалану хокукында бирелгән объектлар өчен | 0,01 |
| «Татарстан Республикасында торак төзелешен үстерүгә дәүләт ярдәме турында» 2004 елның 27 декабрендәге 69-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законын гамәлгә ашыру максатларында төзелә торган торак һәм объектлар урнаштыруга (төзелеш чорын да кертеп) | 0,1 |
| Граждан авиациясе объектлары өчен (төзелеш чорын да кертеп) | 0,1 |
| Махсуслаштырылган стоянкалар (тоткарланган транспорт чаралары стоянкалары (төзелеш чорын да кертеп)) | 0,1 |
| Чистарту корылмалары объектлары өчен (төзелеш чорын да кертеп) | 0,1 |
| Татарстан Республикасы сәламәтлек саклау учреждениеләрендә дәваланучы гражданнарны озата йөрүче затларны вакытлыча түләүсез яшәү өчен билгеләнгән объектлар өчен (төзелеш чорын да кертеп) | 0,1 |
| Су тәэсиренә дучар ителүче гидротехник корылмалар (су ресурсларын файдалану һәм саклау, суларның, шул исәптән сыек калдыклар белән пычранган суларның зарарлы йогынтысын булдырмый калу өчен билгеләнгән су тәэсиренә дучар ителүче гидротехник корылмалар, суднолар йөри торган шлюзлар; судноларны күтәргечләр, су басулардан, сусаклагыч ярларын, елга юллары ярларын һәм төпләрен җимерелүдән саклаучы корылмалар , дамбалар, яр буйларын ныгыту корылмалары, яр буйлары, шул исәптән аларда урнашкан төзекләндерү һәм коммерция инфраструктуралары объектлары, пирслар, техник су белән тәэмин итү корылмалары), аларны булдыру, төзү, | 0,1 |

| | |
|---|---|
| файдалану, реконструкцияләү, модернизацияләү «Концессион килешүләр турында» гы 21 июль, 2005 ел, 115-ФЗ санлы Федераль закон нигезендә төзелгән килешүләр нигезендә тормышка ашырыла(төзелеш чорын да кертеп) | |
| Россия Федерациясе Җир кодексының 39.6 маддәсе, 2 нче пункты, 3 нче пунктчасы нигезендә бирелгән һәм Россия Федерациясе Җир кодексының 39.6 маддәсе, 2 нче пункты, 25нче пунктчасы яки модернизацияләү «Концессион килешүләр турында» - гы 21 июль, 2005 ел, 115-ФЗ санлы Федераль закон нигезендә бирелгән җир кишәрлекләре белән чиктәш булган җир кишәрлекләрендә булдырылган объектлар өчен | 0,1 |
| Россия Федерациясе Җир кодексының 39.6 статьясындагы 2 пунктының 3 пунктчасы нигезендә гамәлгә куючысы Татарстан Республикасы булган табигать территорияләре белән идарә итү буенча юридик затка арендага бирелгән җир кишәрлекләрендә экологик туризм өлкәсендә ял һәм рекреация объектлары өчен (төзелеш чорын да кертеп) | 0,1 |
| Су тәэсиренә дучар ителүче гидротехник корылмалар (су ресурсларын файдалану һәм саклау, суларның, шул исәптән сыек калдыклар белән пычранган суларның зарарлы йогынтысын булдырмый калу өчен билгеләнгән су тәэсиренә дучар ителүче гидротехник корылмалар, суднолар йөри торган шлюзлар; судноларны күтәргечләр, су басулардан, сусаклагыч ярларын, елга юллары ярларын һәм төпләрен җимерелүдән саклаучы корылмалар , дамбалар, яр буйларын ныгыту корылмалары, яр буйлары, шул исәптән аларда урнашкан төзекләндерү һәм коммерция инфраструктуралары объектлары, пирслар, техник су белән тәэмин итү корылмалары), Россия Федерациясе Җир кодексының 39.6 статьясындагы 2 пунктының 25 пунктчасы нигезендә төзелгән аренда шартнамәләре нигезендә 2017 елның 1 гыйнварыннан соң үз акчалары һәм (яисә) заем акчалары исәбеннән төзелә торган (төзелеш чорын да кертеп) | 0,1 |
| Спорт объектлары һәм корылмалары өчен (төзелеш чорын да кертеп) | 0,17 |
| Әгәр әлеге исемлектә башкасы каралмаган булса, Россия Федерациясе Җир кодексының 39.6 статьясындагы 2 пунктының 3 пунктчасы нигезендә юридик затка арендага бирелгән җир кишәрлекләрендә экологик туризм өлкәсендә ял һәм рекреация объектлары өчен (төзелеш чорын да кертеп) | 0,3 |
| Россия Федерациясе Җир кодексының 39.6 статьясындагы 2 пунктының 3 пунктчасы нигезендә бирелгән җир кишәрлекләрендә урнашкан сәламәтлек саклау объектлары өчен | 0,5 (җир кишәрлеген арендалау шартнамәсе төзелгән |

| | |
|---|---|
| | вакыттан алып 5 елга срокка) |
| Россия Федерациясе Җир кодексының 39.6 статьясы нигезендә бирелгән ясалма төзелгән җир кишәрлекләрендә һәм аларга якын җир кишәрлекләрендә объектлар урнаштыру өчен инвестицияләр күләме 350 миллион сумнан да ким булмаган күләмле инвестиция проектын гамәлгә ашыру өчен (төзелеш чорын да кертеп, биш елга) | 1 |
| Авыл хуҗалыгы җитештерүе өчен | 1,0 |
| Торак урнаштыру, шәхси ярдәмче хуҗалык алып бару, бакчачылык, яшелчәчелек өчен үз ихтыяҗлары өчен | 1,0 |
| Җитештерү өлкәсе объектлары өчен (төзелеш чорын да кертеп) | 1,0 |
| Электр станцияләрен, аларның корылмаларына һәм объектларына хезмәт күрсәтә торган объектларны урнаштыру өчен билгеләнгән объектлар өчен (төзелеш чорын да кертеп) | 1,0 |
| Электр станцияләрен, аларның корылмаларына һәм объектларына хезмәт күрсәтә торган объектларны урнаштыру өчен билгеләнгән объектлар өчен (төзелеш чорын да кертеп) | 1,0 |
| Портларны, су, автомобиль юллары вокзалларын, аэровокзалларны урнаштыру өчен билгеләнгән объектлар өчен (төзелеш чорын да кертеп) | 1,0 |
| Файдалы казылмаларны, ясалма рәвештә төзелгән эчке су юлларын, причалларны, пристаньнарны, автомобиль юлларына, су юлларына, торбаүткәргечләргә бүлеп бирелгән полосаларны, кабельле, радиореле һәм һава элемтә линияләрен һәм радиофикация линияләрен, электр тапшыруның һава линияләрен, конструктив элементларны һәм корылмаларны, эксплуатацияләү, тоту, төзү өчен кирәкле объектларны эшкәртү өчен билгеләнгән объектлар өчен, җир өсте һәм җир асты биналарын, төзелмәләрен, корылмаларын, транспорт, энергетика һәм элемтә җайланмаларын реконструкцияләү, ремонтлау, үстерү; җир өсте корылмаларын һәм иярчен элемтә инфраструктурасын урнаштыру (төзелеш чорын да кертеп) | 1,0 |
| Склад объектлары өчен (төзелеш чорын да кертеп) | 1,0 |
| Гаражлар өчен (төзелеш чорын да кертеп) | 1,0 |
| Автомототранспортның күпкатлы ябык һәм җир асты тукталышлары өчен (төзелеш чорын да кертеп) | 1,0 |
| Төзелеш чорына (төзелеш чорын да кертеп)автомототранспортның күпкатлы ябык кую урыннары өчен | 1,0 |
| Рекреацион һәм дәвалау-савыктыру билгеләнешендәге объектлар өчен (төзелеш чорын да кертеп) | 1,0 |

| | |
|---|---|
| Әйләнештәге су объектлары өчен | 1,0 |
| Скверлар, парклар урнашкан объектлар өчен | 1,0 |
| Башка объектлар өчен (төзелеш чорын да кертеп) | 2,0 |
| Административ биналар, биналар һәм офислар өчен (төзелеш чорын да кертеп) | 2,0 |
| Автомототранспортның ачык тукталышлары өчен (төзелеш чорын да кертеп) | 3,0 |
| Күплэп сату объектлары өчен (төзелеш чорын да кертеп) | 4,0 |
| Җәмәгать туклануы объектлары өчен (төзелеш чорын да кертеп) | 4,0 |
| Автосервис объектлары һәм автозаправка станцияләре өчен (төзелеш чорын да кертеп) | 4,5 |
| Кунакханәләр өчен (төзелеш чорын да кертеп) | 5,0 |
| Ваклап сату объектлары (кибетләр, сәүдә мәйданы булган павильоннар, вак ваклап сату киосклары), базар объектлары, даруханәләр (төзелеш чорын да кертеп)өчен | 10,0 |
| Банк, иминият, биржа эшчәнлеге объектлары, шул исәптән түләү терминаллары (төзелеш чорын да кертеп)өчен | 10,0 |
| Сәнәгать-җитештерү тибындагы махсус икътисадый зоналарның идарәче компанияләре (төзелеш чорын да кертеп)идарәсендәге индустриаль парклар инфраструктурасы объектлары өчен | 20 |
| Реклама объектлары (нигездә урнашкан реклама щитлары һәм стендлары (төзелеш чорын да кертеп)) | 75,0 |

**Советның аппарат җитәкчесе** **И.Ю.Монина**